# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 14** **27.11.2022 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге составына керүче Бәйрәкә авылында 2023 елда гражданнар арасында үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегендә гражданнарның Бәйрәкә авылында җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Россия армиясе сафларында хезмәт итүчеләрнең тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 1200 сум күләмендә, ә 2 группа инвалидлар өчен бер тапкыр бирелә торган түләүне киметеп 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләргә юнәлдерергә:

- юлларны грейдерлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчы белән техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылы Вахитов урамындагы юл - урам челтәрен норматив халгә китерү (смета буенча юл төзелеше: вак таш, асфальт сатып алу, нигез салу, ташу, җәю, эш өчен түләү) ;
- Бәйрәкә авылы Сельхозтехника урамындагы зират территориясен ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Бәйрәкә авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылындагы урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү) - карарын кабул ителде дип санарга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О. Әхмәтшина